**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 10 февраль № 78

г. Казань

2017 елда агросәнәгать комплексына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында

«2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2016 ел, 28 ноябрь, ТРЗ-93 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2017 елда авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә үсемлекчелекне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар буенча чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә Татарстан Республикасында орлыкчылыкны үстерүне яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар буенча чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән әче туфракларга известь кертү чараларын гамәлгә ашыру тәртибен;

2017 елда авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә мелиорация эшләре үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда җәнлек үрчетү хуҗалыкларына читлектәге кыйммәтле мех бирә торган җәнлекләрне карап тоту чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда авыл хуҗалыгы җитештерүен техник һәм технологик модернизацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда мелиорация объектларын яңадан техник җиһазландыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең аграр юнәлештәге квалификацияле белгечләр әзерләүгә бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда социаль икмәк җитештерү белән шөгыльләнә торган икмәк пешерү предприятиеләренә он сатып алу һәм (яки) җитештерү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда авыл хуҗалыгы әзерләү-куллану кооперативларының, әзерләү оешмалары һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренең ит, йон һәм күн чималын сатып алу, эшкәртү һәм сату чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөтчелек юнәлешендәге кечкенә фермалар төзүгә чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга башмак таналар һәм тана сыерларның товарлы һәм нәселле баш исәбен сатып алуга чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга яшь кошлар (каз, үрдәк, күркә, бройлер чебиләр) сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга өч яшьтән зур булган бияләрне карап тоту өчен азык сатып алуга чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сыерларга кирәк-ярак җиткерү буенча ветеринария профилактикасы чараларын үткәрүгә чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына оешмалар мөлкәтенә салым түләү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә катнашкан авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә, кулланучылар җәмгыятьләренә, агросәнәгать комплексы оешмаларына, индивидуаль эшмәкәрләргә һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга ягулык-майлау материалларына чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;

2017 елда агросәнәгать комплексы өлкәсендә фәнни тикшеренүләргә һәм эшләргә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан грантлар бирү тәртибен.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына «2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2016 ел, 28 ноябрь, ТРЗ-93 нче Татарстан Республикасы Законында күздә

тотылган ассигнованиеләр исәбеннән 2017 елда конкурс нигезендә агросәнәгать комплексы өлкәсендә фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр алып бара торган милекнең барлык төрендәге оешмаларга 20,0 млн.сум күләмендә бирелә торган грантларның гамәлгә куючысы булырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\78.docx